| | |
|---|---|
| **СОВЕТ**<br>**Исенбаевского сельского поселения**<br>**Агрызского муниципального района**<br>**Республики Татарстан** | **Татарстан Республикасы**<br>**Әгерҗе муниципаль районы**<br>**Исәнбай авыл җирлеге**<br>**СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

28.05.2020 Исәнбай авылы № 57-1

Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына коррупциягә каршы көрәш турында Россия Федерациясе законнарын камилләштерү максатларында үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 16 декабрендәге 432-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 2019 елның 09 декабрендәге 98-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына таянып, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районы прокуратурасының «Исәнбай авыл җирлеге Уставының аерым нигезләмәләренә» 2020 елның 20 гыйнварындагы 02-08-01/27 номерлы протестын үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлеге Советы **карар итте**:

1. Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертүне икенче укылышта кабул итәргә (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны Россия Федерациясе Юстиция министрлыгының Татарстан Республикасы буенча идарәсенә дәүләт теркәве өчен җибәрергә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының Исәнбай авыл җирлегенең рәсми сайтында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында http://agryz.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru урнаштыру юлы белән дәүләт теркәвенә алганнан соң халыкка җиткерергә (игълан итәргә).

4. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң (халыкка җиткерелгәннән) үз көченә керә.

5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемә алам.

Совет рәисе,
Авыл җирлеше башлыгы Ф.Ф.СИРАЕВ

Татарстан Республикасы
Әгерҗе муниципаль районы
Исәнбай авыл җирлеге Советының
28.05.2020 № 57-1
карарына кушымта

**Татарстан Республикасы Әгерҗе муниципаль районының «Исәнбай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр**

**5 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле 20нче пункт өстәргә:**

«20) Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында карар, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында яисә федераль законнарда билгеләнгән капиталь төзелеш объектлары параметрларына туры китерү турында карар кабул итү.»

**29 статьяның 7 өлешен яңа редакциядә бәян итәргә:**

«7. Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатлар түбәндәгеләргә хокуксыз:

«1) шәхсән яисә ышанычлы затлар аша эшкуарлык эшчәнлеге белән шөгыльләнергә;

2) коммерцияле яки коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга, түбәндәге очраклардан тыш:

а) сәяси партия белән идарә итүдә, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан түләүсез нигездә катнашу, башка иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында, күчемсез мөлкәт милекчеләре ширкәтендә катнашу;

б) коммерциягә карамаган оешма идарәсендә (сәяси партия идарәсендә катнашудан тыш, һөнәри берлек органы, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлекнең сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән беренчел профсоюз оешмасының сайланулы органы тарафыннан, башка иҗтимагый оешма, торак, тораактөзелеш, гараж кооперативлары съездында (конференциясендә) яисә гомуми җыелышында катнашу, яллаучы вәкиленең Татарстан Республикасы законында билгеләнгән тәртиптә алынган рөхсәте белән) түләүсез нигездә катнашу;

в) Россия Федерациясе субъекты муниципаль берәмлекләре советында, муниципаль берәмлекләрнең башка берләшмәләрендә, шулай ук аларның идарә органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә күрсәтү;

г) муниципаль берәмлек муниципаль берәмлекне гамәлгә куючы (катнашучы) муниципаль берәмлек булган оешманың идарә органнарында һәм ревизия комиссиясендә оешманы гамәлгә куючы (акционер) тарафыннан оешманы гамәлгә

куючының вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә ашыру тәртибен йә муниципаль милектәге акцияләр (устав капиталындагы өлешләр) белән идарә итү тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә түләүсез нигездә тапшыру;

д) федераль законнарда каралган башка очраклар;».

3) Укыту, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлектән тыш, башка түләүле эшчәнлек белән шөгыльләнергә. Шул ук вакытта укытучылар, фәнни һәм башка иҗади эшчәнлек бары тик чит дәүләтләр, халыкара һәм чит ил оешмалары, чит ил гражданнары һәм гражданлыгы булмаган затлар акчалары исәбеннән генә финанслана алмый, әгәр Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса;

4) Россия Федерациясенең халыкара шартнамәсендә яисә Россия Федерациясе законнарында башкасы каралмаган булса, идарә органнары, попечительләр яисә күзәтү советлары, коммерциячел булмаган хөкүмәтнеке булмаган чит ил оешмалары һәм Россия Федерациясе территориясендә эшләүче аларның структур бүлекчәләре составына керергә.

7.1. Граждан контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасына билгеләнә алмый, ә муниципаль хезмәткәр, муниципаль берәмлек башлыгы белән якын туганлык яисә үзлекләре (әти - әниләр, ирле-хатынлы, балалар, абыйлы-энеле, апалы-сеңелле, шулай ук ире-хатынының абыйсы-энесе, апасы-сеңлесе, әтисе-әнисе, балалары) булган очракта, контракт буенча җирле администрация башлыгы вазыйфасын били алмый.».

**41 статьяның 1 өлешендәге 1 абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:**

«1. Җирлек башлыгы яңа сайланган Советның беренче утырышында, җирлек Советы депутатлары арасыннан, әгәр тавыш бирүнең башка тәртибен билгеләмәсә, ачык тавыш бирү юлы белән билгеләнеп куела.»

**48 статьяның 1 өлешендәге 2 пунктка түбәндәге эчтәлекле 10нчы абзац өстәргә:**

«-үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү турында, үз белдеге белән төзелгән корылманы җимерү яисә аны капиталь төзелеш объектларын рөхсәт ителгән төзүнең, реконструкцияләүнең җир белән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләрендә, территорияне планлаштыру документларында, яисә капиталь төзелеш объектлары параметрларына карата федераль законнарда билгеләнгән мәҗбүри таләпләргә туры китерү турында Россия Федерациясе гражданлык законнары нигезендә карар кабул итә.».